# Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлеге составына керүче Рус Киштәге торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре

20.11.2025 № 2

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә «Кыят авыл җирлегенең Рус Киштәге авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Рус Киштәге авылында каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын урнаштыру, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын урнаштыру) Сез ризамы?» дигән сорау буенча 2025 елның 20 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегендә 119 катнашучы, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 64 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында катнашкан 64 кеше «әйе» позициясе өчен тавыш бирде;

«Каршы» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Буа муниципаль районы Кыят авыл җирлегенең Рус Киштәге авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга.

2. «Кыят авыл җирлегенең Рус Киштәге авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләне хәл итүгә – Рус Киштәге авылында каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын урнаштыру, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын урнаштыру) Сез ризамы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Буа муниципаль районының рәсми сайтында һәм Рус Киштәге авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кыят авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: __________ А.Н.Мишин

Кыят авыл җирлеге башлыгы __________________ А.Н.Мишин